Гыйбадуллина, А. Т. Җырлап ачыла күңел / А. Т. Гыйбадуллина // Ачык дәрес. Мәктәп. – 2025. – №5 (252). – Б. 5-7.



# ҖЫРЛАП АЧЫЛА КҮҢЕЛ

**Гыйбадуллина А.Т.**
Яр Чаллы шәһәре 12 нче китапханә

Танылган эстрада җырчысы һәм композитор Гөлназ Закирова белән очрашу кичәсе.

Салмак музыка уйный, сәхнәгә алып баручылар чыга.

**1 алып баручы:** Сыздыр әле моңлы гармуныңны,
Тарат әле йөрәк сагышын.
Дәртләндереп күңел кылларына
Чиртсен телләреннең тавышы.
Уйна, дускай, уйна гармуныңны,
Күңелләргә кереп уралсын.
Хис-тойгылар аша чыккан моңнар
Халык җыры булып таралсын.
Гармун тавышлары дәртләндереп
Алып кайта яшьлек илемә.
Авылымның тугайларын буйлап
Йөрер идем тагын бер генә.
Гармуннарның серле сагыш моңы
Ургылып чыга гармун теленнән.
Ничә еллар гармун тавышлары
Моңлы җырлар булып түгелгән.
Уйна, дускай, уйна гармуныңны,
Күңелләргә кереп уралсын.
Хис-тойгылар аша чыккан моңнар
Халык җыры булып таралсын.

Хәерле көн, кадерле укучылар! Кеше рухына, күңеленә иң уңай тәэсир иткәне – моң, җыр, музыка. Җыр... Шушы өч хәрефтән торган сүзгә дөнья үзе сыйган кебек. Табигатьнең һәр күренешендә, һәр мизгелендә җыр бар! Безнең һәр күзәнәгебез җыр дигән сихри аһәңне үзенә сеңдерен, башкача тормыш белән яши башлый. Шуңа күрә без, кешеләр, җыр-моңга тартылабыз, аны бик яратабыз. Җыр-моңнан башка яшәү - түбәсез йортта торуга, тозсыз аш ашауга тиң!

**2 алып баручы:** Безнең татар халкы борын-борыннан җырга-моңга хирыс халык. Шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә ул. Татар халкы моңнан яралгандыр, ахрысы. Шулай булмаса, халкыбызның"Караурман","Шахта","Гөлҗамал", "Тәфтиләү", "Әллүки", "Зиләйлүк"ләре булмас иде. Әйтерсең, халык җырларында бөтен үткән фаҗигале татар халкының күңелен нечкәртеп, җанына рәхәтлек бирүче аһәң булып яңгырый, аның йөрәгенә барып житә дә күңелендәге изге хисләрне уята, тетрәндерә. Татар моңсыз яши аламыни?
Татар күңеленә моң кирәк?
Тальяныңны гына сузып җибәр -
Дәррәү кушылыр аңа мең тирәк.
Бәлки, халкым тарих чоңгылыннан
Моңы белән имин үткәндер.
Шул моң аңа сынмас канат булган,
Шул моң аны татар иткәндер.

Укучылар! Бүген бездә кунакта танылган эстрада җырчысы һәм композитор Закирова Гөлназ Илгиз кызы. Гөлназ Закирова 1988 елның 17 июлендә Яр Чаллы шәһәрендә туа. Ул танылган композитор, музыкант, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Закиров һәм гомеренең 40 елдан артык олешен балаларга белем бирүгә багышлаган, М. Вахитов исемендәге 2 нче татар гимназиясе укытучысы Сания Маликовна гаиләсендә туып-үскән талантлы һәм тәрбияле кыз. Тәпи йөри башлаганчы, теле ачылган. Бер яшь тә сигез айда җырлый башлаган. Шундый зур музыкаль гаиләдә, гүзәл Актаныш районының Сөн буенда үскән Гөлназ да кечкенәдән җырга, моңга тартылган. Гөлназ, әңгәмәбезне менә шушы балачак, мәктәп елларын искә төшерүдән башлыйк әле. Кечкенә чакта җырчы булырга хыялланган идеңме?

**1 алып баручы:** Җырлый – җырлый әни оек бәйли
Керосинлы лампа каршында.
Тышта буран, кайчак тынып кала,
Җыр туктагач куба тагын да.
"Чишмәләр дә акмый тынлады" дип
Күтәрдеме минс шигъри моң?
– Нинди көй бу, әни?
-"Рамай", улым,
Йомгак белән башны башка куеп
Йоклап киттем, бүтән дәшмәдем.
Кипте тиздән тарихлардан килеп
Ташып чыккан саф күз яшьләрем.
Җилкендереп һәм тетрәтеп җанны,
Таян, диеп, шушы терәккә,
Моңнар фәрештәсе бер каурыен
Кадап китте нәни йөрәккә.

**2 алып баручы:** Гөлназның музыкант булачагы да балачагыннан мәгълүм булган. Шуңа да 1995 елны Чаллының Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче татар гимназиясенә һәм 6 нчы музыка мәктәбенең фортепиано классына укырга керә. Мәктәптә дә яхшы укый, музыка мәктәбендә

шәһәрдә көчле укытучылардан саналган Розалия Каһармановада фортепиано буенча төпле белем ала. Мәктәп елларында төрле конкурсларда актив катнашып призлы урыннар яулый. «Сандугач керде күңелгә» республика конкурсында - 2 урын, музыка буенча региональ олимпиада - 3урын һәм башка конкурсларда урыннар ала. Ике мәктәпне дә «5» ле билгеләренә генә тәмамлап, 2003 елны Яр Чаллы сәнгать көллиятенең «музыка теориясы» факультетына укырга керә. Гөлназның хыялы, әтисе кебек композитор булып, музыкаль әсәрләр иҗат итү була. Ул 2007 елда Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең композиторлар әзерләү факультетына укырга керә. Әлеге мәртәбәле уку йортын да кызыл дипломга тәмамлый. Яшь булуына карамастан, ул шактый гына уңышларга да ирешергә өлгерә. Гөлназ – композиторлар арасында үткән Салих Сәйдәшев исемендәге республика бәйгесендә лауреат, Дмитрий Кабалевский исемендәге Бөтенроссия конкурсында диплом иясе, халыкара бәйгеләрдә татар халык җырларын башкаручы буларак – “Дуслык моңы 2004”, “Татар моңы 2008”, Галия Кайбицкая исемендәге бәйгедә беренче урын яулый. “Сөн сандугачы 2016” да Гран-при бүләгенә лаек була. Гөлназ, җыр-моң дөньясына ничек килеп кердегез? Профессиональ сәхнәгә, тамашачы тулы залга иң беренче чыккан мизгелне,ниләр хис итүеңне хәтерлисеңме?

(Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**2 алып баручы:** Гөлназның “Серле чишмә” романсын, “Яңгыркаем яу” хореографик картинасын, оркестр өчен “Булгария” симфоник поэмасын, флейта һәм камера оркестры өчен язган житди әсәрләрен сәнгать белгечләре дә, тамашачылар да югары бәяли. “Бер яктан талантлы булган кеше, һәр яктан да оста була”- диләр. Тамашачылар өчен Гөлназның тагын бер таланты – җырлар язу сәләте ачыла. Берсеннән-берсе матур җырлар да иҗат итә.Үзе дә җырларга бик ярата.

**1 алып баручы:** Матур җыр бар, көе моңлы аның,
Син тыңлачы, дустым, иренмичә,
Ул җырны мин җырлап күрсәтәм.
Ул матур җыр җанга ятышлы да,
Үзе моңсу, үзе күңелле.
Ул җыр назлый, иркәли колакны,
Әни бишек җыры шикелле.
Ул җырда бар тургайларның моңы,
Челтер чишмәләрнең тавышы.
Күлләреннән чит илләргә очкан
Киек казларның бар сагышы.
Ул җырымда ялкынлы бер көйдә
И бии ки ләйсән яңгыры.
Я кышларның, җанга сафлык чәчеп,
Моңсу гына ява ак кары.
Ул матур җыр туган як турында...
Мин бит аны җанда йөретәм.
Тыңлап кара, дустым, иренмичә,
Шул җырымны җырлап күрсәтәм.

Гөлназ, безнең яшь тамашачыларыбызга үзеңнең берәр матур җырыңны башкаруыңны сорыйбыз.

(Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**2 алып баручы:** Үзенең чибәрлеге белән сәхнәне бизәүче, моңлы һәм көчле күкрәк тавышы белән тамашачы күңелен яулаучы Гөлназны тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Сәнгатьне зурлап, кадерләп иҗат итеп, аны сакларга тырышып, шул эшкә күңелен биреп яши, иҗат итә. Әле аның аеруча тулышып, күңеле үзгә бер кичерешләргә төренеп яшәгән серле һәм бик бай мәле. Сиңа моң чишмәсе каян килә? Репертуарында нинди җырлар бар?

(Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**1 алып баручы:** Омтылган – зурга омтылыр, омтылмаган – онытылыр, диләр. Алга таба үзеңә нинди максатлар куйдың? Тылсымлы таягың булса нишләр идең?

(Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**1 алып баручы:** Безнең артистыбыз турында остазлары, хезмәттәшләре, сәнгать белгечләре тарафыннан бик яхшы сүзләр әйтелә:

«Гөлназ – горурланырлык укучыларымның берсе. Ул тырышлыгы һәм максатчанлыгы белән башкалардан һәрчак аерылып торды. Һәрвакыт белемгә һәм камиллеккә омтылды. Дәресләргә җаваплы карады, әйткән киңәшләребезне үзенә сеңдереп барды. Аңа фәкать «Афәрин» дип, уңышлар гына телим», – ди шәкерте белән горурланып Эльвира Ногманова. «Гөлназның әнисе турындагы җырын ишетеп, иҗатына гашыйк булган идем. Ул кечкенәдән максатчан булды. Шундый талантлы, тырыш балалары булган милләтебез югалмас, Аллаһы боерса» – ди татар теле укытучысы Нәзлия Вәҗиева.

«Гөлназның әтисе-әнисе белән дус булып яшибез, Аллага шөкер. Кызларыбыз да дуслар. “Алма агачыннан ерак тәгәрәми” диләр, Гөлназ күпкырлы талант, унган кеше, аның иҗатта әтисен уздыруына ышанам. Ул – профессиональ җырчы гына түгел, матур җырлары белән күңелләрне

айкый торган композитор да. Кызым Лилиягә әниләргә багышланган җырын биргән иде, беренче тыңлаганда да ук еладым. Гөлназ иҗатта да, шәхси тормышында да бәхетле булсын иде» ди - Татарстанның атказанган артисткасы Гөлдания Хәйруллина.

**1 алып баручы:** Моң нечкәртә икән күңелләрне
Һәм елата икән, җырлата.
Сагыну илләренә озата да
Сөелү иңнәрендә сызлата.
Моң дәвалый икән күңелләрне:
Сихәт бирә, искә төшерә.
Яшәүләре авыр булыр иде
Моң булмаса җирдә кешегә.

**2 алып баручы:** Кеше гомерләре юллар кебек,
Җырлар кебек кеше язмышы.
Куандыра шатлыклары,
Үкендерә ялгышы.
Җырлыйк әле, дуслар, җырлыйк әле,
Кайгы-хәсрәтләрне таратып.
Моңга чорнап дөньяларны,
Нурга чорнап, яратып.

Гөлназ, безнең тамашачыларга синнән матур җыр. (Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**1 алып баручы:** Җыр – татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәнле матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Җырларым – утлы учакмы,
Очкыннар чәчеп тора.
Яну һәм сүнү бәхетен
Җаның белән генә үрел,
Яктысын тоя – тоя.
Җырларым нигәдер бүген
Йөрәккә очкын коя....

**2 алып баручы:** Бүгенге җылы кичәбез ахырына якынлашты. Кунагыбыз җырчы һәм композитор Гөлназ Закировага иҗади уңышлар телибез. Яңа җырлары белән тамашачыларны сөендерүен дәвам итсен.

**1 алып баручы:** Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

# БӨЕК ҖИҢҮ КАЙТАВАЗЫ

**Шәехова Алмазия Зиннур кызы**
Яр Чаллы шәһәре 12 нче китапханә

Бөек Ватан сугышының 80 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә

**Алып баручы:** Мәңгелек ут яна. Шул утларда
Күпме язмыш яна, күпме яра.
Киләчәккә имин барыр өчен,
Үткәннәргә бер борылып кара.

Хәерле көн, укучылар! Һәр яңа көн туды исә, без бер-беребезгә имин, тыныч көннәр телибез. Мин дә менә сезгә: «Хәерле көн!» — дип эндәшәм. Узган һәрбер көнебез, кылган барлык гамәлебез хәерлегә булсын. Көннәр, еллар бер-бер артлы үтә тора. Алда Бөек Җиңүнең 80 еллыгы. Бәйрәмнәрнең иң олысы, иң кадерлесе - әлбәттә, Җиңү бәйрәме.

Күп корбаннар хакына, зур югалтулар бәрабәренә яуланган Җиңү ул! Тарих бу кадәр булган афәтне башка хәтерләми. Рәсми мәгълүматларга караганда, илебез бу сугышта 27 млн кешесен югалткан, 1700 шәһәр хәрабәгә әйләнгән, 10 мең авыл җир белән тигезләнгән. Димәк, анда яшәүчеләрнең ачы язмышын күзалларга була.

1941 нче елның 22нче июнь таңы. Гүзәл авыллар, шәһәрләр татлы йокыда. Шул вакытта немец фашистлары илебез чикләрен бозып кереп, авылларны, шәһәрләрне утка тоталар. Бөек Ватан сугышы башлана.

Үткән гомер — аккан су, искән җил, диләр. Ә менә Бөек Ватан сугышының данлы үткәне аның үлемсез каһарманнары без бервакытта да истән чыгарырга хаклы түгел. Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар» әсәрен күпләрегез хәтерлидер :анда түбәндәге юллар бар:

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исемем сезгә житмәс — онытылыр...

Әйе, «Исемем сезгә житмәс — онытылыр», — ди шагыйрь. Шөкер Һ.Такташның кем икәне билгеле, аның бөек шагыйрь икәнен онытмадык.

Сезнеңчә, 1418 көн, 1418 төн буена барган сугыш кайтавазы, җиңелүләр, җиңүләр, югалтулар, батырлыклар онытылырга тиешме? Киләчәк буыннарга бу көннәр, вакыйгалар турында житкерә алырбызмы соң?

**1 укучы:** Тып-тын дала.
Моннан сугыш үткән.
Кан коелган монда,
Кан аккан.
Тәмуг кебек ялкын дөрләп янган,